КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 29 декабрь г.Казань № 1191

2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 29 декабрь, 1191 нче
карары белән расланды

2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – Фонд, субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Бюджет акчасын алучы буларак Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен 2025 елда субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Субсидия күләме әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен 2025 елга Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар суммасы буларак билгеләнә.

4. Субсидия бирү ысулы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

5. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәге чыгымнар керә:

ишегалды территорияләрен төзекләндерү объектларының проект-смета документациясен эшләү;

юл эшләрен башкару;

урам яктырткычларын урнаштыру;

кечкенә архитектура формаларын урнаштыру;

«Бипиум» мәгълүмат системасына хезмәт күрсәтү;

төзелеш контроле;

Фонд эшчәнлеген тәэмин итү хезмәтләре өчен түләү.

7. Субсидия бирүгә заявка бирелгән айның 1енче көненә Фонд түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Берләшкән Милләт Оешмасы уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы яки Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлары булмый яисә бурычы Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга

салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (Фондка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, Фондка карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки Фондның баш бухгалтеры турында мәгълүматлар юк.

8. Субсидия алу өчен Фонд Министрлыкка әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча Фонд җитәкчесе (аның йөкләмәләрен үтәүче зат) тарафыннан кул куелган, түбәндәге документлар теркәлгән заявка тапшыра:

финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чыгымнары Фонд тарафыннан гамәлгә ашырылуны чагылдыра торган, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча төзелгән 2026 елга Фондның финанс планы;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр кертү турындагы документларның күчермәләре;

Фонд җитәкчесенең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләре;

салым органында исәпкә куелу турында документның күчермәсе.

Фонд, заявка белән бергә, үз теләгенә карап, түбәндәге документларны Министрлыкка тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсен;

заявка бирү датасына кадәр өч айдан да иртәрәк булмаган вакытта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтә күчермәсен;

салым органы тарафыннан заявка бирү планлаштырыла торган айның беренче көненә карата Россия Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турында белешмә кәгазен.

Документлар электрон мәгълүмат йөрткечтә бирелә. Барлык документлар да төгәл басылырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (Фонд җитәкчесенең имзасы белән таныкланган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми.

Тапшырыла торган белешмәләрнең дөрес булмавы өчен Фонд Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

9. Министрлык:

Фондның заявкасын кергән көнендә документлар әйләнеше кагыйдәләре нигезендә терки;

заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Фондның заявкасын тикшерә һәм тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7 һәм 8 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Фондка кабул ителгән карар турында хәбәр итә;

субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган документларны, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Фондка кире кайтара.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

Фонд тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Фонд тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү;

Фондның әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве.

11. Субсидия бирү Министрлык белән Фонд арасында төзелгән килешү (алга таба – килешү) нигезендә башкарыла. Килешү, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган сигезенче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә һәм, әлеге системада документлар бирүнең һәм карауның техник мөмкинлеге тәэмин ителгән очракта, һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана. Техник мөмкинлек булмаган очракта, килешү якларның имзалары куелып кәгазь документ рәвешендә һәм мөһерләре булганда төзелә.

«Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурадагы идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү сроклары һәм тәртибе;

Фонд тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм өстәмә хисаплар (кирәк булганда) бирү тәртибе һәм сроклары;

Фондның, Фонд белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы.

субсидияне кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт;

Фонд, шулай ук Фонд белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю турында шарт;

субсидия бирү тәмамлануның төгәл датасы һәм аның нәтиҗәсе күрсәткечләре.

Килешүгә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт кертелә.

Субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләренең Министрлыкка элек җиткерелгән лимитлары кимегән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү карала торган яисә яңа шартлар буенча килештерелмәгәндә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзелә.

Кирәк булганда Министрлык Фонд белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

12. Фонд кушылу, кушу яки үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Фондны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук коммерциягә карамаган оешма бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, Фонд тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

13. Субсидия бирү нәтиҗәсе – 2026 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасында кимендә 500 ишегалды территориясен төзекләндерү эшләрен башкару.

14. Субсидия күчерү, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Фонд тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына гамәлгә ашырыла.

15. Фонд квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Министрлык әлеге пункт нигезендә тапшырылган хисапларны мондый хисаплар тапшырылган көннән алып 5 эш көненнән артмаган срок эчендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

16. Министрлык Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

17. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

18. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш (Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаны әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрү ихтыяҗы булган очракта, Фонд Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, шундый ихтыяҗны нигезләп, мәгълүмат бирә.

Министрлык, субсидия алучыдан әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Фондның агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

19. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган очракларда;

әгәр Фонд тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән булса, субсидия алучы субсидия акчасын түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә (V) кире кайтара:

$$V = S \times k,$$

монда:

S – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме, сум;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{t}{n},$$

монда:

t – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткечләре;

n – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткечләре.

Субсидия акчасын кире кайтару күләме исәпләп чыгарылганда коэффициентның бары субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәү дәрәҗәсе чагылдырыла торган уңай мәгънәләре кулланыла.

20. Субсидияне кире кайтару срогы бозылганда Министрлык срок чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

21. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

____________________________________________

____________________________________________
(җитәкченең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) фамилиясе,
__________________________________ тан (нан)
исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) (тулысынча)

Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә
заявка

1. Тулы исеме: Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фонды (алга таба – Фонд) ______________________________

2. Фондның юридик адресы: ____________________________________________
_____________________________________________________________________________
телефоны: _________________ e-mail: ___________________________________

3. Фонд җитәкчесенең (вәкаләтле затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), вазыйфасы: ___________________________________________
телефоны: _________________ e-mail: ___________________________________

4. Фонд тарафыннан башкарыла торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат:
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

5. Фондның реквизитлары:
салым түләүченең идентификация номеры: ______________________________
исәпкә куелу сәбәбенең коды: _______________________________________
төп дәүләт теркәү номеры: __________________________________________
исәп-хисап счеты: _________________________________________________
банкның исеме һәм урнашу урыны: ___________________________________
корреспондент счеты: ______________________________________________

банк идентификация коды: ___________________________________________

6. Фондка карата түбәндәгеләр дип раслыйм:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Берләшкән Милләт Оешмасы уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы яки Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, _______ _______ нчы карары белән расланган 2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлары булмый яисә бурычы Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан

Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (Фондка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, Фондка карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки Фондның баш бухгалтеры турында мәгълүматлар юк.

7. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://minstroy.tatarstan.ru) Фонд турында, Фонд тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүмат, Фонд турында башка мәгълүмат бастырып чыгару (урнаштыру) өчен ризалык бирәм.

Фонд җитәкчесе (вәкаләтле зат) _______________ __________ ___________________
(вазыйфа) (имза) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы __________________________ __________ ___________________ _____________
(вазыйфа) (имза) (имзаны таркатып язу) (телефоны)

20___ ел, «___» __________

2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

## Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондының финанс планы

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Ишегалды территориясен төзекләндерү объектының адресы һәм исеме | Каты өслекләр мәйданы, кв.метр | Юл эшләрен башкару кыйммәте, сум | Кече архитектура формаларын урнаштыру кыйммәте, сум | Урам яктырткычларын урнаштыру кыйммәте, сум | Гомуми кыйммәте, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барысы бергә, шул исәптән: | | | | | | |
| | проект-смета документациясен эшләү кыйммәте | | | | | | |
| 1. | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | |
| …. | | | | | | | |

Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фонды җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат)
_____________/ _____________________________________________/
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

М.У.

Дата: 20__ елның «__» __________